Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XVII-2**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 29 декабре

2022 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын раслау турында

Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру максатларында, “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 24 июлендәге XX-10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турындагы Нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның кушымта итеп бирелә торган Фараз планын (программасын) расларга.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына 2022 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) билгеләнгән тәртиптә тормышка ашыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
4. Карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы И.Р.Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының елның
номерлы
карары белән расланды

2022 елга
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы)

## 1 бүлек. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру өлкәсендә сәясәтне тормышка ашыруның төп юнәлешләре һәм бурычлары

2022 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы) Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Граждан кодексы, “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Конкуренцияне яклау турында” 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру мәсьәләләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 24 июлендәге XX-10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турындагы Нигезләмә нигезендә эшләнде.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру программасының төп юнәлеше (алга таба текст буенча - муниципаль мөлкәт) булып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль мөлкәт белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм хосусыйлаштыру процессының планлы булуын тәэмин итү тора.

Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру программасы түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдереләчәк:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы икътисадының тулаем һәм аерым хуҗалык субъектлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;
- муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырудан планлаштырылган барлык керемнәрнең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына үзвакытында һәм тулысынча керүе;
- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының милек структурасын оптимальләштерү һәм, нәтиҗә буларак, муниципаль мөлкәт белән идарә итүгә бюджет чыгымнарын кыскартуга, шул исәптән рентабельле булмаган объектларны тотуга һәм эксплуатацияләүгә чыгымнарны киметү;
- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы икътисадын һәм аның инфраструктурасын үстерү өчен инвестиция чараларын җәлеп итү;

- Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген үстерүгә һәм бизнесны озак вакытка үстерүгә һәм яңа эш урыннары булдыруга юнәлтелгән нәтиҗәле милекчеләр формалаштыруга ярдәм итү.

2020-2021 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы) гамәлдә булу срогы дәвамында аңа Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелергә мөмкин.

Ел дәвамында хосусыйлаштырылмаган муниципаль милек объектлары киләсе елга фаразлау планына кертелә.

## 2 бүлек. 2022 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль мөлкәт объекты исемлеге һәм сыйфатламасы

2022 елга хосусыйлаштыру программасы нигезендә түбәндәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру күздә тотыла:

| № п/п | Аталышы | Урнашу урынының адресы | Саны (данә) | Функциональ билгеләнеше | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | FIAT DUCATO автобусы, таныклау номеры (VIN)- Z7G244000AS020720, төсе: сары | Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп. | 1 данә | Балалар йөртү өчен махсус, М2 категориясе, класс В | Ирекле |

Хосусыйлаштыру программасын гамәлгә ашыру sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгында аукцион уздыру юлы белән гамәлгә ашырылачак, шул исәптән ул бәяләү эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә билгеләнгән муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру ысулларын һәм хосусыйлаштыруның башлангыч бәясен үз эченә ала.

Әлеге программада каралган хосусыйлаштыру шартлары турында карар кабул итү муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк.